Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге составына керүче Әбсәләм тимер юл разъезды торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

21 ноябрь 2024 ел №5

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 21 ноябрендә узган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, ире (хатыны), балалары), Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендәге Тынычлык урамына вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?» - соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 16 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 9 кеше, бу 56,3% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 9 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, ире (хатыны), балалары), Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендәге Тынычлык урамына вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?»-соравы буенча гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хакимият һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» сайтында http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева